ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2026 елның 15 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында» 2007 елның 13 ноябрендәге 58-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 11; 2010, № 12 (II өлеш); 2014, № 4; 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 78 (I өлеш); 2023, № 56 (I өлеш); 2024, № 76 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяда:

а) 1 өлештә:

өченче абзацта «республика дәүләт хакимияте органнары» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «республика дәүләт хакимияте органнары өчен» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары өчен» сүзләренә алмаштырырга, «республика дәүләт хакимияте органнарының дәүләт мәгълүмат системаларын» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системаларын» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «республика дәүләт хакимияте органнары» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт органнары» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 өлешнең икенче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт органнары» сүзләренә алмаштырырга;

2) 7 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Мәгълүмат системаларына түбәндәгеләр керә:

1) дәүләт мәгълүмат системалары:

а) федераль законнар, Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте актлары нигезендә төзелгән федераль мәгълүмат системалары;

б) Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары актлары нигезендә төзелгән Татарстан Республикасы мәгълүмат системалары;

2) җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә төзелгән муниципаль мәгълүмат системалары;

3) башка мәгълүмат системалары.»;

б) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:

«$1^1$. Татарстан Республикасы дәүләт органнары үз эшчәнлеген оештыру ягыннан, мәгълүмати, документлар, финанс белән һәм техник тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системалары булмаган мәгълүмат системалары (алга таба – дәүләт органнарының башка мәгълүмат системалары) төзи. Дәүләт органнарының башка мәгълүмат системалары Татарстан Республикасы дәүләт органнарының хокукый актлары нигезендә төзелә.»;

3) 8 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системалары «Дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законда, Россия Федерациясе бюджет законнарында йә дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык хакындагы Россия Федерациясе законнарында, концессия килешүләре турындагы законнарда каралган таләпләрне исәпкә алып, ә Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системаларыннан Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын җәлеп итмичә генә файдаланган очракларда башка федераль законнар нигезендә төзелә, яңартыла һәм файдаланыла.»;

4) 9 статьяда:

а) исемдә «төзү» сүзеннән соң «һәм эксплуатацияләү» сүзләрен өстәргә;

б) 2 өлештә «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы Федераль законда» сүзләреннән соң «(алга таба – Федераль закон)» сүзләрен өстәргә;

в) 3 – 5 өлешләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Муниципаль мәгълүмат системаларын эксплуатацияләү федераль законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

4. Дәүләт мәгълүмат системалары яисә муниципаль мәгълүмат системалары булмаган мәгълүмат системаларын төзү һәм эксплуатацияләү тәртибе мондый мәгълүмат системалары операторлары тарафыннан Федераль законда яисә башка федераль законнарда билгеләнгән таләпләр нигезендә билгеләнә. Әлеге өлешнең нигезләмәләре дәүләт органнарының башка мәгълүмат системаларына кагылмый.

5. Дәүләт органнарының башка мәгълүмат системаларын төзү һәм эксплуатацияләү тәртибенә карата таләпләр Федераль закон нигезендә билгеләнә.»;

5) 10 статьяда:

а) 2 өлештә «мәгълүмат системасын булдыруга дәүләт контрактын төзегән заказчы» сүзләрен «мәгълүмат системасын төзү заказчысы» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2[1] өлештә «эксплуатацияләү һәм яңарту» сүзләрен «яңарту һәм эксплуатацияләү» сүзләренә алмаштырырга;

в) 7 өлештә «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы Федераль законның» сүзләрен «Федераль законның» сүзләренә алмаштырырга;

6) 15 статьяның 2 өлешендә «дәүләт учреждениеләренең башка мәгълүмат системаларындагы мәгълүматны» сүзләреннән соң «, шулай ук Федераль законның 13 статьясындагы 5[1] өлеше нигезендә техник чаралар һәм электрон исәпләү машиналары һәм белешмәләр базалары өчен программалар кулланганда мәгълүматны» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон 2026 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2026 ел, 25 апрель
№ 27-ТРЗ